ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«22» декабрь 2022 ел

№ 1126

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 мартындагы 184 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 декабрендәге 1002 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 ноябрендәге 587 номерлы карарын үтәү йөзеннән Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 мартындагы 184 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Спорт резервын әзерләүче оешмалар хезмәткәрләренең төп окладларны билгеләү

1. Спорт резервын әзерләүче оешмалар хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айга төп оклад күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Төп гомуми белем, урта гомуми белем | Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән расланган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | - | 16 142 | 18 362 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-оештыручы | - | 16 149 | 18 382 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-психолог | - | 16 155 | 18 382 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек мөдире (башлыгы): гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту- | - | - | 18 463 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | консультация пункты, укыту (җитештерү) остаханәсе һәм башка структур бүлекчәләр | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | - | - | 18 526 |

2. Спорт резервын әзерләүче оешмаларның мәдәният хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә

| Вазыйфа исеме | Айга төп оклад күләме, сум | | |
|---|---|---|---|
| | Төп гомуми белем, урта гомуми белем | Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән расланган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| "Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Аккомпаниатор | 16 388 | 16 899 | 17 199 |
| "Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Тавыш операторы | 16 388 | 17 399 | 19 899 |
| Рәссам-бизәүче | | | |

3. Спорт резервын әзерләүче оешмаларның медицина хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айга төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 17 200 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы | 18 900 |
| "Табиблар һәм провизорлар" һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиблардан тыш) | 20 600 |

-------------------------------
<*> Вазыйфа өч һәм аннан да күбрәк шәфкать туташлары булган очракта оешмада билгеләнә.

4. Спорт резервын әзерләүче оешмалар хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айга төп оклад күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Төп гомуми белем, урта гомуми белем | Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләр әзерләү программалары буенча | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән расланган югары белем |

| | | | урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт залы буенча дежур | 15 279 | - | - |
| | I төркем инвалид спортчыны озата баручы | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Спортчы | 15 279 | - | - |
| | Әйдәп баручы спортчы | | | |
| Икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Адаптив физик культура инструкторы | 15 279 | 16 142 | 18 362 |
| | Спорт инструкторы | - | 16 142 | 18 362 |
| | Спортчы-инструктор | 15 279 | | - |
| | Тренер -җайдак | 15 279 | 16 142 | - |
| | Спорт техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау техникы | - | 16 142 | - |
| Икенче квалификация | Күнегүләр процессы администраторы | - | 16 149 | 18 382 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| дәрәҗәсе | Физкультура-спорт оешмалары инструкторы | - | 16 149 | 18 382 |
| | Адаптив физик культура буенча инструктор-методист | - | 16 149 | 18 382 |
| | Тренер | - | 16 149 | 18 382 |
| | Адаптив физик культура буенча тренер-укытучы | | 16 149 | 18 382 |
| | Хореограф | - | 16 149 | 18 382 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист | - | 16 155 | 18 394 |
| | Физкультура-спорт оешмалары өлкән инструктор-методисты | - | 16 155 | 18 394 |
| | Адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы | - | 16 155 | 18 394 |
| Өченче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Аналитик (спорт төрләре төркеменә яисә төренә карап) | - | - | 18 562 |

5. Спорт резервын әзерләүче оешмаларның авыл хуҗалыгы вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айга төп оклад күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Төп гомуми белем, урта гомуми белем | Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән расланган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Икенче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Ветеринария фельдшеры | - | 16 855 | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Үсемлекләрне саклау буенча агроном (уртача квалификация) | | | |
| Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Агроном | - | - | 17 411 |
| | Зоотехник | | | |
| | Ветеринария табибы | | | |
| Икенче | II категорияле агроном | - | - | 17 466 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| квалификация дәрәҗәсе | II категорияле зоотехник | | | |
| | II категорияле ветеринария табибы | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | I категорияле агроном | - | - | 17 521 |
| | I категорияле зоотехник | | | |
| | I категорияле ветеринария табибы | | | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Әйдәп баручы агроном | - | - | 17 576 |
| | Әйдәп баручы зоотехник | | | |
| | Әйдәп баручы ветеринария табибы | | | |
| Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Баш агроном | - | - | 18 302»; |

27 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27 нче таблица

Спорт резервын әзерләүче оешмалар җитәкчеләренә башкарган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр һәм төп окладлар күләме

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү төркеме | Күләм күрсәткече (муниципаль бирем нигезендә агымдагы елның 1 сентябренә торышы буенча шөгыльләнүчеләр саны), кеше | Төп оклад, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | 0 - 200 | 25 000 | 2 000 |
| 2 | 201 - 400 | 27 000 | 3 000 |
| 3 | 401 - 700 | 31 000 | 3 000 |
| 4 | 701 - 1 200 | 32 000 | 4 000 |
| 5 | 1 201 - 1 800 | 35 000 | 5 000 |
| 6 | 1 801 һәм аннан югарырак | 37 000 | 6 000 |

-------------------------------
<*> спорт резервын әзерләүне оештыру укчылары контингенты (спорт-җайлашу мәктәбе) 3 коэффициенты белән исәпкә алына»;

Әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары гомумтармак җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары гомумтармак җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

1. Спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айга төп оклад күләме, сум |
|---|---|
| "Беренче дәрәҗә гомумтармак һөнәрләре" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 15 279 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 15 477 |
| "Икенче дәрәҗә гомумтармак һөнәрләре" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 15 618 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 15 792 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 15 970 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 16 501 |

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айга төп оклад күләме, сум |
|---|---|
| "Беренче дәрәҗә гомумтармак хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 15 279 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 15 477 |
| "Икенче дәрәҗә гомумтармак хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 15 618 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 15 792 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 15 970 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 16 197 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 16 383 |
| "Өченче дәрәҗә гомумтармак хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 16 573 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 16 766 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 16 963 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 17 164 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 17 390 |
| "Дүртенче дәрәҗә гомумтармак хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |

| | |
|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 18 302 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 18 502 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 18 702 |

3. Хезмәткәрнең вазыйфасы һәм һөнәре квалификация дәрәҗәсенең гомумтармак эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркеменә туры килүе федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителә.

4. Кушып эшләүче, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү, башкарылган эш күләменә карап, пропорциональ эшләнгән вакытка яисә башкарылган эш күләменә карап башкарыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук кушып эшләү тәртибендәге вазыйфа буенча хезмәт хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазыйфа буенча аерым башкарыла».

VI бүлекнең 7 пунктындагы 7.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 17 октябрендәге 2245-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә спорт резервын әзерләү концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын үтәгәндә спорт резервы әзерләүче оешмалар хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә һәм икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә төп эш һәм төп вазыйфа буенча, акча булган очракта, бер тапкыр түләнә торган түләү башкарыла.

Түләүнең тәртибе, шартлары һәм билгеле бер күләме күрсәтелгән максатларда спорт резервын әзерләүче оешмаларның локаль норматив актлары белән билгеләнә.";

VIII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, спорт резервын әзерләүче оешманы гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.";

6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

"6. Спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесе урынбасарына, баш бухгалтерына башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр аларның эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, спорт резервын

әзерләүче оешма җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарына, баш бухгалтерга башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, бер ел эшләү йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен кертелергә мөмкин. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрнең иң чик күләме спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесенә башкарган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүнең 70 процентына кадәр күләмдә билгеләнә.";

9 пунктның беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9. Спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесенә тренерлар тарафыннан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм ярышларда спортчылар һәм спортчы-инструкторлар алган нәтиҗәләр өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр күрсәтелгән оешманы гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесе урынбасарына, баш бухгалтерга тренерлар тарафыннан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм ярышларда спортчылар һәм спортчы-инструкторлар алган нәтиҗәләр өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр күрсәтелгән оешма җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

2. Әлеге карарның 1 пунктының 1.1 пунктчасы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш. Вафинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М.Гатиятов